# XX-XXI ГАСЫР ЧИКЛӘРЕНДӘ Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНЫҢ ӨЙРӘНЕЛҮ ТОРЫШЫ

Г. Тукай иҗаты – хәзерге көн татар әдәбияты белемендә зур кызыксыну уяткан һәм өйрәнелгән өлкәләрнең берсе. Аның иҗатын өйрәнүнең бер гасырлык бай, катлаулы, вакыты белән каршылыклы тарихы бар. Тукай рухи мирасын гыйльми-нәзари күзаллауга һәм бәяләүгә XX гасырда иҗтимагый-җәмгыяви җилләр, сәяси вәзгыять зур йогынты ясап тора. Ләкин, Совет әдәбият белеменең марксистик-ленинчыл тәгълиматка нигезләнгән методологиясе шагыйрь лирикасының иҗтимагый, сыйнфый йөзен алгы планга чыгара. Тукай иҗатын өйрәнүгә җәмгыятьтәге иҗтимагый вәзгыять, әдәбият белемендә кабул ителгән идеологик һәм норматив принциплар зур йогынты ясый.

Тукай гыйльмиятен формалаштыруга Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Ф. Бурнаш, И. Нуруллин, Г. Халит, М. Гайнуллин, Н. Хисамов, Р. Ганиева, Т. Галиуллин һәм башкалар зур өлеш кертә.

Тукай иҗатын өйрәнүнең һәр чоры мәгълүм үзенчәлекләргә, билгеле бер тенденция, закончалыкларга ия. Аның үсеш тарихында әдәбият галимнәре төрле баскычларны аерып чыгаралар. Мәкаләдә Тукай фәне үткән юлның XX-XXI гасыр чикләрендәге үсеш-үзгәреш закончалыкларына игътибар юнәлтелә.

Тукай гыйльмиятенең бүгенге көндәге торышы, һичшиксез, 1980 елларда М.С. Горбачев исеме белән бәйле булган демократик, ярымдемократик үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнгән. Советлар Берлегенең таркалуы, марксистик-ленинчыл идеологиянең хакимлеге кире кагылу, илдә кискен иҗтимагый-рухи, әдәби-мәдәни үзгәрешләр башлануга шартлар тудыра. Әдәбият киңлекләрендә – әдәбият белеме фәнендә дә яңарыш хәрәкәте башлана. Татар әдәбият фәнендә моңа кадәр өйрәнелгән һәм бәяләнгән шагыйрьләрнең, язучыларның да рухи мирасларын яңача күзаллау бурычы куела. Шушы уңайдан, татар әдәбятының классигы, милли һәм халык шагыйре Габдулла Тукайның иҗатын да яңача шәрехләү мәсьәләсенә игътибар юнәлтелә. Бу юнәлештә Ф. Мусин, Н. Хисамов, Р. Ганиева, Ә. Сәхапов, Т. Галиуллин, Ф. Галимуллин, Х. Миңнегулов, Э. Галиева, Д. Заһидуллина, Ф. Яхин, Т. Гыйлаҗев, Н. Йосыпова һәм башкалар нәтиҗәле эшләделәр. Шулай итеп, 1990 еллар башында Тукай феноменын, шагыйрьнең шәхесен, әдәби мирасын аңлауда яңа чор башлана.

Габдулла Тукай иҗатында иҗтимагый-социаль мәсьәләләр калку гәүдәләнсә дә, ул халык, милләт шагыйре булып кала бирә. Шагыйрь рухи мирасының башыннан алып ахырына кадәр кызыл җеп булып милли тема яктыртыла. Аның рухи мирасында, киңкырлы эшчәнлегендә милли, фәлсәфи, дини-әхлакый характердагы әдәби әсәрләр дә бер катлам тәшкил итә.

Тукай шигъриятен милли, гомуммилли идея яссылыгында шәрехләү мәсьәләсе Ф. Мусин, М. Хәсәнов, М. Зәкиев мәкаләләрендә күтәрелә. Аннан тыш, шагыйрь поэзиясенең милли характерын ачуда М. Сәхапов Г. Тукай иҗатының халык авыз иҗаты белән бәйләнешенә игътибарын юнәлтә. Тукай иҗатына нигезләнеп татар әдәбият белемендә, әдәбият-сәнгатьтә миллилек принцибы хакында фәнни-

теоретик караш барлыкка килүне дә XX-XXI гасыр чикләрендә Тукай фәненең уңышы рәвешендә карарга мөмкин.

Тукайның дөньяга карашын ачыклау проблемасы да көн тәртибенә куела [4: 83]. Тукай иҗатын тирәнтен өйрәнгән галимә Р. Ганиева: "Шагыйрь Габдулла Тукайның дөньяга карашларын XX гасыр башында тамыр җәйгән социалистик хәрәкәтләр тарихыннан аерып карау мөмкин түгел", - дип яза [3:102]. Габдулла Тукай – халыкчы, милләтче. Әмма аңа иҗтимагый фикер киңлеге, дөньяга карашлар төрлелеге хас. Шуның белән бергә каршылыклы фикерләр тууга сәбәпче булган социалистик идеяләр дә чит түгел. Т.Ш. Гыйлаҗев: "Ике гасыр чигендә, ниһаять, Г. Тукайның дини карашлары, Аллага, Коръән тәгълиматына мөнәсәбәте мәсьәләсендә дә ачыклык кертелде булса кирәк", - дип белдерә [4:84]. Чынлыкта да, олуг әдипнең Аллага чын күңелдән ышануы, ислам диненә зур хөрмәт белән каравы, дини тәрбия алган булуы беркем күңелендә дә шик тудырмый.

Р. Ганиева, Х. Миңнегулов, Н. Хисамов, Д. Заһидуллина, Н. Исмәгыйлов, Ч. Зарипова, Т. Гыйлаҗев һәм башкаларның хезмәтләрендә Г. Тукайның дини карашлары, Аллага, Коръән тәгълиматына мөнәсәбәте мәсьәләләренә ачыклык кертелә. Олуг әдипнең Аллага чын күңелдән ышануы, ислам диненә зур хөрмәт белән каравы, дини тәрбия алган булуы мисаллар белән дәлилләнә. Моңа бәйле рәвештә, галимнәрнең хезмәтләрендә Г. Тукай иҗатының Ислам мәдәнияте белән бәйләнеше, аның бай әдәби мирасына Коръәннән үтеп кергән гомумкешелек кыйммәтләр, дини мотивларның чагылышы хакында нәтиҗәләр ясала.

Ике гасыр чигендә эш иткән тукайчы галимнәр, Тукай үз иҗатында Урта гасыр һәм XIX гасыр мәгърифәтчелек әдәбияты, Шәрекъ классикасының бай традицияләрен үстерде, Көнбатыш Европа һәм рус эстетикасы белән кушты, һәм милли әдәбиятны дөнья әдәбияты аренасына гыгуын тәэмин итте дигән нәтиҗәгә киләләр.

Р. Ганиева, Х. Миңнегулов һәм башкаларның тикшеренүләрендә Тукай әсәрләрендә суфыйчыл карашларның тасвирланышы, сәнгатьчә гәүдәләнеше ассызыклана [5:335]. Д. Заһидуллинаның "Дөнья сурәте үзгәрү" (2006) монографиясендә бу юнәлештә сыйфади сикереш ясала. Галимә дәлилле мисалларга таянып, Тукай шигъриятендә төрле фәлсәфи концепцияләрнең чагылышын билгели һәм бу фәнни-теоретик карашлар, кануннар шагыйрь иҗатында төрле дөнья сурәтләренең чагылышына китергән дигән нәтиҗә ясый.

Тукай фәнен яңартуда, аның офыкларын киңәйтүдә фәнни-гамәли конференцияләрнең дә роле бик зур. Аларда тәкъдим ителгән темалар шагыйрь турында фәннең төрле аспектларын яктырталар, билгеле бер күләмдә, Тукай иҗатын өйрәнүдә чишмә башы вазифасын да үтәделәр. Мәсәлән, 1996 елда шагыйрьнең 110 еллыгы, 2011 елда 125 еллыгы уңае белән үткәрелгән фәнни конференцияләр, 1998-2010 елларда Тукай җәмгыяте тарафыннан ел саен даими үткәрелеп килүче "Тукай укулары", 2011 елның халыкара төрки мәдәниятләр оешмасы – ТӨРКСОЙ тарафыннан Татарстан Республикасында һәм ТӨРКСОЙ Халыкара оешмасына кергән илләрдә **бөек һәм олуг татар шагыйре Габдулла**

**Тукай истәлеген һәм иҗади мирасын мәңгеләштерү максатларында “Габдулла Тукай елы” дип игълан ителүе дә** бик әһәмиятле.

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап шуларны әйтергә мөмкин: XX-XXI гасыр чикләрендә Тукай иҗатын өйрәнүдә яңа сыйфатлар барлыкка килә. XX гасырның 90 елларында идеологик, сәяси нормалар кире кагылу сәбәпле, Г. Тукайның шәхесен, мирасын аңлауда фәннилек, объективлылык принципларына таяныла башланды. Төп игътибар аның шагыйрьлек асылын, дәрәҗәсен, татар әдәбиятын яңартудагы ролен, татар халкының рухи-мәдәни тормышындагы урынын ачыклауга гыйльми күзаллауга юнәлтелде. Г. Тукай рухи дөньясын иҗтимагый-милли, әдәби-эстетик, дини-фәлсәфи планда өйрәнү юнәлеше яңара бара.

**Әдәбият:**


1. Галиуллин Т.Н. Шигърият баскычлары. – Казан: Мәгариф, 2002. – 20-46 б.
2. Галимуллин Ф.Г. Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.
3. Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 112 б.
4. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.
5. Миңнегулов Х.Й. Гасырлар өнен тыңлап. – Казан, 2003. – 335 б.